Чыганак: Мәгариф. - 2012. - № 9. - С. 57-59



# 1812 ЕЛГЫ ВАТАН СУГЫШЫНДА ТАТАРЛАР



**Илшат ФӘЙЗРАХМАНОВ, Ш.Мәрҗани исемендәге тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты**

1812 елның июнендә Наполеонның Россиягә басып керүе ил өчен гаять зур куркыныч тудыра. Сугышның беренче көннәреннән үк Россия халкында патриотик хисләр көчәеп китә. Шул исәптән татар халкы да, бөтен ил халкы белән бергәттән, Наполеонга каршы көрәшкә күтәрелә.

Петр I чорыннан алып 1874 елга кадәр татар халкы армиягә рекрутлар җибәреп торган. 1793 — 1834 елларда армиядә хезмәт итү вакыты 25 ел тәшкил итә. Гадәти елларда мең кешедән 5 — 7 кеше армиягә алынса, сугыш алдыннан һәм сугыш вакытында көчәйтелгән (1 мең ревизия җанынnan 7 — 10 кеше) һәм өстәмә (1 мең ревизия җанынnan 70 кешегә кадәр) рекрут наборлары үткәрелә. 1812 елда 3 набор була: 82 нче (1 мең кешедән 4 әр рекрут), 83 нче (1 мең кешедән 20 рекрут), 84 нче (1 мең кешедән 16 рекрут)[1]. Регуляр армия составындагы татарлар Наполеонны җиңүгә зур өлеш кертә.

1812 елның сентябрендә Казан ополчениесен җыю башлана. Ополчениегә крепостной крестьяннар (100 кешедән 4 се) алына. Дәүләт крестьяннары, шул исәптән татарлар, ополчениегә чакырылмый, шулай да шәһәрдә яшәүче мещаннардан, һөнәрчеләрдән баручылар була. Мәсәлән, Нигабидуллина фамилияле мещан хатыны ополчениегә олы улын биргәч, Татар ратушасына барып, кече улын да ополчениегә алуларын сорап йөргән[2].

1812 елның көзенә Казанга Мәскәүдән һәм Смоленскидан 30 меңләп качаклар килеп тула. Казанда аларны бик мөлаем каршы алалар: монастырьларга урнаштыралар я шәһәр халкы үз йортларына кертә.

Сугыш башыннан алып, армиягә, ополчение һәм сугыштан зыян күрүчеләргә ярдәм акчалары җыю башлана. Казан губернасы буенча гомуми иганә җыемнары 346 мең сум тәшкил итә. Аерым кешеләр тарафыннан җыйналган алтын-көмеш арасында татар хатын-кызларының бизәнү әйберләре дә була. Армия өчен кирәк-ярак җыю ирекле-мәҗбүри характерда үткәрелә. Казанның татар общинасыннан 1812 елның 3 июленә 2 нче Кострома пехота полкын оештыруга 4100 сум җыела. 1812 елның 21 августында Татар шәһәр ратушасына караган сәүдәгәрләрдән мәҗбүри 8360 сум җыю карала. Әгәр дә шәһәрнең бөтен рус мещан сословиесе 10 мең сум тирәсе ярдәм акчасы җыйнавын исәпкә алсак, бу сумма аз булып күренми[3].

Франция белән сугыш башланыр алдыннан Казандагы күпчелек сәүдәгәрләр Мәкәрҗә ярминкәсенә киткән була. Монда алардан Түбән Новгород ополчениесенә ярдәм акчасы җыела. Ярдәм күрсәтүчеләр исемлегендә бөтен илдән: Түбән Новгородтан, Мәскәү, Казан, Тобольск, Иркутск һ.б. җирләрдән килгән сәүдәгәрләр үз имзаларын куйган. Мәсәлән, алар арасында Казанның 1 нче гильдия сәүдәгәре Муса Апанаев (520 сум), Малмыжның 1 нче гильдия сәүдәгәре Муса Үтәмешев (500 сум), Арчаның 1 нче гильдия сәүдәгәрләре Мөхәммәтрәхим Мәмәшев, Мортаза Абурнаев, Габделкәрим Бакаров (100 әр сум) һ.б. бар.

1812 елның 8 августында Мәкәрҗә ярминкәсенең Татар сабын рәтеннән генә дә Казанның татар һәм рус сәүдәгәрләреннән 5690 сум җыеп алына. Мәкәрҗә ярминкәсе барышында барысы 72746 сум җыела. Чагыштыру өчен: Түбән Новгород губернасы буенча җыемнарның гомуми күләме сугыш чорында 875 мең сумнан артып киткән[4].

---

[1] Полное собрание законов — Собрание 1-е, 1830, Т.32, № 25198.

[2] **Городчанинов Г.** Казанское ополчение // Республика Татарстан. — 2002. — 12 сент.

[3] **Валиуллин И.** На пожертвование в пользу Отечества (Татарская община г. Казани в 1812 г.) // Гасырлар авазы — Эхо веков. — 2009. — № 1. С. 10 — 12.

[4] **Сенюткина О.Н., Загидуллин И.К.** Нижегородская ярмарочная мечеть — центр общения российских и зарубежных мусульман (XIX — начало XX вв.). Нижний Новгород, 2006. С. 30.

Татарларның бер өлеше регуляр булмаган хәрби формированиеләр составында сугыш хәрәкәтләрендә катнаша.

Французларга каршы башкортлар, мишәрләр, типтәрләр, татарлардан булган казаклардан торган полклар генераллар П.Багратион, А.Тормасов, М.Барклай де Толли армияләре составында көрәшкән. Анда хәрби көчләрнең өч төркеме: башкорт һәм мишәр полклары, Оренбург казак гаскәре, типтәр казак полклары була.

Россия тарихында аеруча билгеле хәрби формированиеләрдән башкорт һәм мишәрләрдән торган полкларны атап үтәргә кирәк. 1798 елда 1 нче һәм 2 нче башкорт атлы полклары Пермь, Оренбург һәм Вятка губерналарында кантон системасы төзелгәч оештырыла[5]. Аларны Оренбург линиясе буенча чик саклауда файдаланалар.

1812 елның 25 июль боерыгы нигезендә 3, 4, 5 нче башкорт полклары оештырыла. Шул ук елның июлендә Оренбург казак гаскәре атаманы В.Углецкий өстәмә атлы полклар төзү тәкъдиме белән чыга. Аның тәкъдимен Александр I хуплый, инде 1812 елның август-сентябрендә 1 нче, 2 нче мишәр һәм тагын 15 (6 нчы — 20 нче) башкорт полкы оештырыла. Һәр полкта 530 кеше (500 рядовой, полк башлыгы, старшина, 5 есаул (ул чорда казак гаскәрләрендә офицер чины), 5 сотник, 5 хорунжий, 10 пятидесятник, квартирмейстер, писарь һәм мулла) була[6].

Башкорт һәм мишәр полкларының үз мундирлары булмаган, алар үзләренең милли киемнәрендә, сөңге, кылыч, ук-җәя белән коралланып, походка чыккан. Мылтык һәм пистолетлар бик сирәкләрендә генә була. Башкорт полклары күпсанлы бәрелешләрдә: французларны Россиядән куганда, Березина янындагы бәрелештә, рус армиясенең чит илгә походында, 1813 елның 4 — 7 октябрендә булган «Халыклар сугышы» дигән исем белән тарихка кереп калган Лейпциг сугышында һ.б. җирләрдә активлык күрсәтә, әсирләрне саклап озата бара, каравыл һәм тәртип саклау вазифаларын башкара[7].

Оренбург казак гаскәре күп милләт вәкилләреннән торган. 1799 елда гаскәргә Оренбург губернасының ясаклы крестьяннары һәм татарлары кертелә. Французларга каршы Оренбург казак полклары составында, татар-мөселманнардан тыш, нугайбәкләр — чукындырылган татарлар төркеме катнаша. Алар походтан кайткач, туган якларында оештырган яңа бистәләрне үзләре җиңеп үткән Европа шәһәрләре исемнәре белән: Париж, Берлин, Фершампенуаз, Арси, Кассель дип атый.

Типтәр полклары XVIII гасыр ахырында статуслары буенча, оешкан вакытыннан алып, регуляр һәм иррегуляр кавалерия арасында була. Бер яктан, аларны армия мундиры, коралы, билгеле бер хезмәт итү срогы (15 ел) якынлаштырса, икенче яктан, полкның тәэмин ителеше, аның типтәрләр һәм ялгызаклар сословиесеннән генә оешкан булуы, униформа, чиннар һәм оешу процессы ук аңа иррегуляр характер бирә[8].

Сугыш башланганда 1 нче типтәр полкы генерал М.Барклай де Толлиның 1 нче Көнбатыш армиясе составында була. Бородино сугышында әлеге полк М.Платов һәм Ф.Уваров җитәкчелегендәге рус атлы гаскәренең французлар тылына рейдта катнаша. 1812 елның сентябрь-октябрь айларында хәзерге Калуга өлкәсендә һәм янәшәдәге Смоленск, Мәскәү өлкәләрендә 1 нче типтәр полкы, башка частьлар белән берләттән, актив хәрәкәт итә. Аларга дошман тылына һөҗүмнәр оештыру, француз армиясен азык-төлек, корал белән тәэмин итүне тоткарлау, мародерлар белән көрәш вазифалары йөкләнә[9].

2 нче типтәр полкы 1812 елның сентябрендә Денис Давыдовның партизан отряды составында Вязьма шәһәре янында һәм Яңа Смоленск юлында французларга каршы хәрәкәт итә. Аннары полк ополчениедә хезмәт итүчеләрдән һәм иррегуляр гаскәрләрдән торган махсус корпус составында Смоленск губернасында дошманга каршы сугыша.

Күп кенә татар сугышчылары армия командирларының югары бәяләмәсенә лаек була. Мәсәлән, Вязьма өчен сугышта 1 нче типтәр полкы есаулы Сәгыйть Халитов үзен таныта, III дәрәҗә Изге Анна ордены белән бүләкләнә[10]. Рославльдә күрсәткән батырлыклары өчен полк командиры майор Тимеров — IV дәрәҗә Изге Владимир ордены, прапорщик Монасыйпов III дәрәҗә Изге Анна ордены белән бүләкләнә, зауряд-хорунжий Ибраһимовны хорунжий чинына күтәрәләр[11].

---

[5] Полное собрание законов — Собрание 1-е, 1830, Т.27, №8477.

[6] **Усманов А.Н.** Башкирский народ в Отечественной войне 1812 г. — Уфа, 1964. С. 56.

[7] **Бекмаханова Н., Кобландин К.** Французской кавалерии лучше бы не сходиться со степняками // Татарский мир. — 2002. — № 3. С. 5.

[8] **Рахимов Р.Н.** История тептярских конных полков. 1790 — 1845. — Уфа, 2008. С. 188.

[9] **Ахметшин Ш.К., Насеров Ш.А.** Татары на службе Отечеству. Долг. Отвага. Честь. Страницы истории татарских воинских частей в Российской армии и Императорской гвардии. — СПб., 2006. С. 165 — 166.

[10] **Бекмаханова Н., Кобландин К.** Күрсәтелгән хезмәт. С. 5.

[11] Народное ополчение... С. 161, 162.

1814 елның 18 мартында 4 нче һәм 5 нче башкорт, 1 нче һәм 2 нче типтәр полклары Россия гаскәре составында Парижга бәреп керә. Әлеге полк сугышчылары «1814 елның 19 мартында Парижны алган өчен» дигән көмеш медальләргә лаек була.

Шулай итеп, чик буен саклауда зур тәҗрибә туплаган атлы типтәр полклары бәрелешләрдә һәм кавалерия атакаларында үзләренең югары дәрәҗәдә хәрби әзерлекле булуларын күрсәтә.

Наполеон гаскәрләрен җиңүгә кырым татарларының 4 атлы полкы да зур өлеш кертә. Бородино сугышында атлы татар полклары, французларның тылларына рейд ясауда катнашып, сугышка француз император гвардиясенең керүен тоткарлый[12].

1812 елда Россия регуляр кавалериясе составында Польша һәм Литва татарларыннан торган Татар улан полкы була. Татар улан полкы сугыш башында генерал А.Тормасовның 3 нче резерв армиясе авангардына керә, 1812 елның җәендә полк Кобрин янындагы, Литвадагы Городечке авылы тирәсендәге сугышларда катнаша, Наполеонның төп көчләре белән очрашуы французларның Березина елгасын кичеп чыккан мәлендә була. Татар полкының җиңел һәм җитез уланнары дошман гаскәренең флангларына котмәгәндә һөҗүм итә һәм шунда ук кире үз позицияләренә кайта[13].

Литва татарларының Наполеон ягында сугышучылары турында да әйтеп китәргә кирәк. 1812 елда Наполеон армиясе составына кергән аерым татар эскадроны (штаты: майор, 4 капитан, 7 лейтенант һәм сулейтенант, 110 түбән чин) полковник Мостафа Әхмәтович командалыгында сугыша. Вильноны саклаганда эскадрон зур югалтулар кичерә: 10 офицерын һәм 50 рядовоен югалта. Француз полкы составында эскадрон Германия, Франция территорияләрендә сугыш хәрәкәтләрендә катнаша, 1815 елда ватанына кире кайтарылгач, таратыла[14].

Татар солдатларының французларга каршы сугышулары «Любизар», «Голубец, молодец» кебек халык җырларында урын алган[15]. Патриотизм идеяләре белән сугарылган «Рус-француз сугышы бәете»ндә татарларның рус армиясе җиңүенә керткән өлеше ачык чагыла[16]:

[...] Французлар килеп кергән Мәскәү
дигән калага
Безнең гаскәр килгәчтен, алар качты
далага [...]
Урамнарын тутырса да французлар
Мәскәүнең,
Унике типтәр бетерде французның
гаскәрен.
Дүрт-биш кердек сугышка, каннар
билдин актылар,
Сугышларны бетергәч, безгә медаль
тактылар.
Французның атлары бар да ефәк
тышаулы;
Французның солдатлары офицерга
охшаулы [...]
Французлар монда килгән, таныдылар
үзләрен,
Уңда — башкорт, сулда — типтәр,
табалмыйдыр эзләрен.
Французның илләре, түгәрәк икән
күлләре,
Французларны куганда үттек без күп
илләрне [...]
Французның атлары кырын җирдә
дулыйдыр,
Башкорт белән типтәрләр французны
турыйдыр [...]
Наполеонның эшләпәсе канга
тапланган иде;
Без сугыштан кайтканда илләр
шатланган иде [...]

Шулай итеп, 20 башкорт (аларның 13 е хәрби хәрәкәтләрдә катнаша), ике типтәр һәм 2 нче мишәр полклары, 4 кырым-татар, Татар улан полклары 1812 елгы Ватан сугышында һәм аннан соңгы 1813 — 1814 еллардагы чит ил походларында катнаша. Әлеге полкларда мөселман руханилары, дини хезмәтләрен башкарып, сугышчыларны батырлыкка рухландырган. Ватан өчен көрәштә Россия халыклары арасында дуслык ныгыган.

---

[12] **Масаев М.В.** К годовщине Бородинского сражения. Крымскотатарские конные полки в Отечественной войне 1812 года и в заграничных освободительных походах русской армии 1813 — 1814 годов // Отечество. — 1998. — № 6. С. 4.

[13] **Ахметшин Ш.К., Насеров Ш.А.** Татары на службе Отечеству. Долг. Отвага. Честь... С. 140 — 151.

[14] **Гришин Я.Я.** Татарский след в истории Литвы и Польши (XIV — XIX вв.). — Казань, 2005. С. 74 — 75.

[15] Татар халык иҗаты. Тарихи һәм лирик җырлар. — Казан, 1988. 44, 45 б.

[16] Татар халык иҗаты. Бәетләр. — Казан, 1983. 39, 40 б.